**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

№ 21 22 ноября 2019 ел

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2017 елның 12 декабрендәге 10 санлы карары белән расланган «2018-2019 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген көчәйтү» федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында» 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р санлы боерыгын тормышка ашыру максатында

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2017 елның 12 декабрендәге 10 санлы карары белән расланган «2018-2019 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Программаны финанслау» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме 250, 584 мең сум тәшкил итә.

Муниципаль бюджетлардан финансларны бүлүче – авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе, район Башкарма комитеты Җитәкчесе. Финанслауның күрсәтелгән күләме тиешле финанс елына бюджет формалаштырганда төгәлләштерелергә тиеш. Моннан тыш, мөмкин булганда, район бюджеты акчалары, максатчан һәм ирекле иганәләр җәлеп ителәчәк.»;

1.2. 2018-2020 елларга Биклән авыл җирлеге буенча юл хәрәкәте иминлеген көчәйтү программасын яңа редакциядә бәян итәргә:

2018-2020 елларга Биклән авыл җирлеге буенча юл хәрәкәте иминлеген көчәйтү программасы

| № | Объект исеме | Ераклык | Финанслау чыганаклары | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Җирле бюджет, сумнарда | | | |
| | | | 2018 | 2019 | 2020 | |
| 1 | Авыл эчендәге юлларны төзү, ремонтлау һәм реконструкцияләү: | - | | | | |
| 1.1 | Чкалов урамы, Биклән авылы (чокырларны ремонтлау) | 2,0км | - | - | – | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2 | Чкалов һәм Әхмәтшин урамнарын тоташтыручы авыл эчендәге юл | 0,1 км | – | – | 99,00 | |
| 2 | Җирлек торак пунктларында тукталыш павильоннарын урнаштыру | | – | – | – | |
| 3 | Җирлектә гомуми белем бирү учреждениеләре каршында балалар автомобиль мәйданчыклары | | – | – | – | |
| 4 | «Ясалма тигезсезлек» урнаштыру: | | – | – | – | |
| 4.1 | Чкалов урамында мәдәният йорты, фельдшер-акушерлык пункты каршында | | – | – | – | |
| 4.2 | Магариф урамында СП, янгын депосы каршында | | – | – | – | |
| 5. | Юлның машиналар йөрү өлешенә разметка | | – | – | – | |
| 6. | Авыл җирлегендә юл билгеләре урнаштыру | - | – | – | – | |
| 6.1 | Биклән авылында җәяүлеләр кичүендә светофор урнаштыру | | | 52,584 | | Биклән авылында 52 584 мең сумлык кояш электростанциясе(светофор) куелды |
| **7** | Юл буе сервисы объектлары булган участокларда юлларны яктырту | - | – | - | - | |
| **7.1** | Авыл эчендәге юлларда яктырткычлар урнаштыру | | 99,0 | | | |
| 8 | Металлдан барьер коймалар урнаштыру | - | – | – | – | |
| | БАРЛЫГЫ | | 99,0 | 52, 584 | 99,00 | |

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе М.Ш.Сәхбеев